КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 11 июль г.Казань № б-1538

Татарстан Республикасы Рәисенең «А.С.Пушкин тууының 225 еллыгын бәйрәм итү турында» 2023 елның 22 мартындагы 176 номерлы Указын үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2024 елда Татарстан Республикасында А.С.Пушкин тууының 225 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча төп чаралар планын (алга таба – чаралар, план) расларга.

2. Чараларның җаваплы башкаручыларына 2024 елның 5 декабренә кадәр план чараларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына мәгълүмат кертергә.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына 2024 елның 12 декабренә кадәр план чараларын гамәлгә ашыру барышы турындагы җыелма мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 июль, б-1538 нче боерыгы белән расланды

2024 елда Татарстан Республикасында А.С.Пушкин туууының 225 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча төп чаралар планы

| Т/с | Чара | Үткәрү срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| I. Төп юбилей һәм тантаналы чаралар | | | |
| 1. | «Пушкин ФЕСТ» рус мәдәнияте фестивале (концертлар, спектакльләр, лекцияләр, иҗади очрашулар, күргәзмәләр, мастер-классларны үз эченә алган чаралар циклы) | 2024 елның июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 2. | «Календарь битләрен карап» циклыннан «Друзья мои, прекрасен наш союз!» концерты (Пушкин даирәсе шагыйрьләренең шигырьләренә җырлар һәм романслар) | 2024 елның феврале | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 3. | Республика «Пушкин балы» | 2024 елның феврале | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең «Н.И.Лобачевский исемендәге Лицей» гомуми белем бирү интернат мәктәбе (килешү буенча) |
| 4. | «Пушкин һәм фән» фәнни бергәлеге катнашында программалар циклы | 2024 елның апреле | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 5. | «Как во городе было во Казани» концерт программасы (театрда һәм кинода А.С.Пушкин сюжетлары) | 2024 елның апреле | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 6. | А.С.Пушкин әсәрләре буенча фильмнар күрсәтү | 2024 елның 6 мае – 24 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Таркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 7. | «Черек күл» паркында «Пушкин һәм халык мәдәнияте» театральләштерелгән халык йөрүләре | 1224 елның 12 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 8. | Балалар өчен интерактив программалар циклы (халык уеннары) | 1224 елның 12 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 9. | «Там на неведомых дорожках» («У Лукоморья дуб зеленый…») театральләштерелгән бәйрәм тамашасы | 2024 елның 17 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музейтыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе . |
| 10. | Рус теле көнен һәм бөек рус шагыйре А.С.Пушкин тууының 225 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чара | 2024 елның 6 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 11. | Казан шәһәрендә А.С.Пушкин һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасы | 2024 елның 6 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 12. | «Кино һәм музыка» проекты кысаларында мәктәп укучылары өчен «Пушкин – безнең барысы да!» интерактив уены | 2024 елның 6 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Таркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 13. | А.С.Пушкин әсәрләрен укуга багышланган әдәби акция | 2024 елның 6 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 14. | А.С.Пушкинның туган көненә багышланган «Китап-Фест-2024» китап фестивале | 2024 елның 6 июне | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), «Казан шәһәренең Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе (килешү буенча) |
| 15. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә А.С.Пушкинның тууының 225 еллыгына багышланган чаралар циклы | 2024 елның 1 – 6 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 16. | А.С.Пушкин тормышына һәм иҗатына багышланган лекцияләр циклын үткәрү | 2024 елның июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 17. | «Его перо любовью дышит» әдәби кунакханәсе | 2024 елның июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Республика яшүсмерләр китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 18. | «Болдино көзе» төбәкара балалар һәм яшүсмерләр театр фестивале | 2024 елның октябре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, башкарма комитет |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы, «Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 19. | «Александр Пушкин. Ун төп әсәр» лекцияләр циклы | 2024 ел дәвамында ай саен | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| II. Күргәзмә проектлары | | | |
| 20. | «Мимо острова Буяна в царство славного Салтана…» интерактив инклюзив күргәзмәсе (Свияжск җирендә А.С.Пушкин әкиятләре, башка халык һәм әдәби әкиятләр) | 2024 елның июне – августы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 21. | А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына багышланган «Казан губернасы буенча А.С.Пушкинның иҗат сәяхәте» виртуаль күргәзмәсе | 2024 елның июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 22. | А.С.Пушкин тууының 225 ел тулуга багышланган китап күргәзмәләрен оештыру һәм үткәрү | 2024 елның июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре, муниципаль китапханәләр (килешү буенча) |
| 23. | Татарстан Республикасы буенча Пушкин маршруты (А.С.Пушкин, рәссам Н.С.Данилевский оныклары катнашында) | 2024 елның октябре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты, «Зе- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | ленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 24. | Татарстан Республикасы музейларында һәм уку йортларында экспонатлаштыру өчен мультимедиа контенты белән «Пушкин һәм Казан» күчмә (модульле) күргәзмәсе | 2024 ел дәвамында | Е.А.Боратынский музее – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы |
| III. Фәнни, мәгълүмат һәм нәшрият проектлары | | | |
| 25. | «Онегин укулары» XV республика фәнни-гамәли конференциясе | 2024 елның гыйнвары | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) «Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 26. | А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына эссе конкурсы («Минем Пушкин») | 2021 елның феврале – июне | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 27. | «Пушкин укулары» XVI Бөтенроссия ачык конкурсы һәм гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм педагоглары өчен «И чувства добрые я лирой пробуждал» республика семинары | 2024 елның 18 марты | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Яр Чаллы шәһәренең «А.С.Пушкин исемендәге 78 нче лицей» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 28. | А.С.Пушкин һәм аның замандашлары иҗатына багышланган «Боратынскийлар усадьбасында әдәби укулар – 2024» бөтенроссия фәнни конференциясе | 2024 елның 18 – 20 апреле | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Е.А.Боратынский музее – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы |
| 29. | «А.С.Пушкин әсәрләрендә субъект һәм шәхес категориясе» түгәрәк өстәле | 2024 елның апреле | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 30. | «Пушкин цифрлы киңлектә: тарихи хәтерне саклау технологияләре» фәнни-гамәли конференциясе | 2024 елның апреле | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 31. | Педагогларның «Пушкин укулары: заманча караш» фәнни-гамәли конференциясе | 2024 елның сентябре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 32. | «А.С. Пушкин педагогикасы: шагыйрь мирасыннан педагогика фәненә» II Халыкара педагогика форумы | 2024 елның сентябре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) «Зеленодольск муниципаль районының А.С. Пушкин исемендәге 9 нчы лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 33. | Урта уку йортлары укытучылары өчен «Пушкин һәм Казан: биографиянең һәм иҗатның Казан контекстлары» методик басмасы | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Е.А.Боратынский музее – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы |
| 34. | Пушкинның һәм рус әдәбиятының «алтын гасыр» иҗатын өйрәнүчеләрне чакырып, «Пушкин лекториясе» музей-мәгариф мәгълүмат программасы | 2024 ел дәвамында ай саен | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Е.А.Боратынский музее – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы |
| 35. | Республика Кирилл-Мефодий яшьләр фәнни укулары | 2024 елның мае | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| IV. Башкару сәнгате өлкәсендәге чаралар | | | |
| 36. | «Рус шигърияте кояшы» шигъри марафоны: чит ил студентлары А.С.Пушкин шигырьләрен дөнья телләрендә укыйлар | 2024 елның 21 феврале | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 37. | «Комлы тарихлар» «Пушкин әкиятләре» балалар абонементы концерты | 2024 елның 10 марты | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 38. | А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына багышланган «Рус поэзиясе кояшы» сәнгать атнасы | 2024 елның мае | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 39. | «Классикларны укыйбыз» проекты | 2024 елның 1 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 40. | «Студентлар марафоны» яшьләр фестивале кысаларында «Пушкин әсәрләре» бию конкурсы | 2024 елның ноябре | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 41. | «А.С.Пушкинның тормышы һәм иҗаты» викторинасын үткәреп һәм, спектакль караганнан соң, тамашачылар белән аның турында фикер алышып, «Салтан патшасы турында әкият» спектаклен күрсәтү | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Әкият» татар дәүләт курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 42. | «Людмила и Руслан» спектаклен күрсәтү | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 43. | «Капитан кызы» спектаклен күрсәтү | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 44. | А.С.Пушкин, аның дуслары һәм замандашларына багышланган «Ак зал музыкасы» музей проекты кысаларында «Друзья мои, прекрасен наш союз!» музыкаль кичәләре циклы (Татарстан Республикасының атказанган артисткасы Ю.Җиһаншина катнашында) | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Е.А.Боратынский музее – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы |
| 45. | Казан шәһәренең бер мәктәбенә А.С.Пушкин исемен бирү | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| VI. Ярдәм итә торган һәм мәгълүмати чаралар | | | |
| 46. | «Пушкин укулары» республика фестивале | 2024 елның феврале | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Казан шәһәре Мәскәү районының «20 нче гимназия» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 47. | «Пушкин укулары» бөтенроссия иҗат эшләре конкурсы | 2024 елның марты | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Яр Чаллы шәһәренең «А.С.Пушкин исемендәге 78 нче лицей» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 48. | «Пушкин һәм Казан» дигән җәяүле экскурсия | 2024 елның мае | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт коми- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | теты, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| 49. | Театр артистлары «Пушкинны укыйбыз» туры эфирында А.С.Пушкинның әсәрләрен укый | 2024 елның 6 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Әкият» татар дәүләт курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 50. | Казан шәһәренең билбордларында, мәгълүмат афишаларында һәм метрополитенында социаль реклама урнаштыру | 2024 ел дәвамында | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| VII. Өстәмә чаралар | | | |
| 51. | «А.С.Пушкин исемендәге гомуми белем бирү оешмалары берлеге» ассоциациясе утырышы | 2024 елның 14 апреле | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 52. | «Улица Пушкина» һәм «Пушкин урамы» проектлары | 2024 елның II кварталы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 53. | Казандагы Пушкин урыннары буенча очерклар яки «прогулкалар» | 2024 елның II кварталы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 54. | Халыкара балаларны яклау көне кысаларында А.С.Пушкин әкиятләре буенча театральләштерелгән тамашалар | 2024 елның 1 июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 55. | Пушкин тыюлыгын төзекләндерү буенча хәйрия ярдәме күрсәтү өчен «Пушкиногорье дуслары» ихтыярилар отряды сәфәре | 2024 елның 25 июне – 25 июле | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Яр Чаллы шәһәренең «А.С.Пушкин исемендәге 78 нче лицей» муниципаль автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 56. | «Пушкин һәм Пугачев эзләре буенча» экскурсия | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 57. | «А.С.Пушкин Казанда» лекцияләр циклы | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 58. | А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына багышланган яңа спектакль иҗат итү һәм спектакльне күрсәтү | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Буа дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе |
| 59. | Татарстан Республикасы рус теле буенча «Тоталь диктант» халыкара мәгариф акциясендә катнашу | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 60. | Рус теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларда, конкурсларда һәм конференцияләрдә җиңүчеләр һәм лауреатлар өчен «Глагол» республика профильле сменасы | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| VII. Китап-каталог һәм сувенир продукциясе чыгару | | | |
| 61. | А.С.Пушкин әсәрләре персонажлары белән китап кыстыргычларын чыгару | 2024 елның апреле – июне | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 62. | «А.С.Пушкин исемендәге мәгариф оешмалары» җыентыгын бастырып чыгару (проект географиясе: Россия Федерациясе, БДБ илләре һәм дөньяда А.С.Пушкин исемендәге рус мәктәпләре) | 2024 елның июне | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 63. | «Татарстан рәссамнары иҗатында «Пушкин Казанда» открыткаларын җыю («Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең фонд коллекциясеннән) | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Е.А.Боратынский музее – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы |
| 64. | А.С.Пушкин юбилеена һәм аның әйләнә-тирәсенә багышланган истәлекле автор открыткаларын чыгару | 2024 ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицее» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |

____________________